


**Ахметова Мансура Габдулловна**- старшая сестра Мансура Габдулловича Ахметова. Родилась в деревне Бизяки Бондюжского района Татарской АССР. Ее отец Ахметов Габдулла был бригадиром колхоза им.Сталина в с.Бизяки и в первые же дни Великой Отечественной войны ушел на фронт. К сожалению, ему не суждено было вернутся- он пропал без вести в 1942 году. Их мать Рахима апа одна подняла двоих детей: старшую Мансуру и младшего Мансура, обоим сумела дать высшее образование. Эта сельская семья уникальна тем, что из нее вышли два кандидата наук, один народный артист Республики Татарстан. Всех их

бизякинцы помнят талантливыми, добрыми, обаятельными, готовыми помочь каждому.

Мансура апа после работы в Бизякинской средней школе переехала работать в Москву и защитила там диссертацию **кандидата педагогических наук.**

Более подробно о Мансура апа Вы прочитаете ниже в отрывке из книги Рамзии Гараевны Мухутдиновой **«Укытучым, кадерлем».**

# Аккоштай сылу зат



Күбәләктәй очып-очып, сәхнәдә ак күлмәкле бер кыз бии. Аның җитез хәрәкәтләрен, аяклары белән тыпырдап алуларын, бөтерелә-бөтерелә әйләнүләрен күреп-күзәтеп бетереп булмый кебек. Ә ул, үзенең тиешле хәрәкәтләрен төгәлләп, тыйнак кына баш ия дә, сәхнә артына кереп югала.

Клуб тулы тамашачыны оста биюе белән әсир итүче кем ул? Халык кемгә шулай гөрләтеп кул чаба?

Бу – Мансура Әхмәтова, Бәзәкә мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы.

Мансура Габдулла кызы Әхмәтова 1935 елда Бәзәкә авылында крестьян гаиләсендә туа. Мансурага алты яшь булганда, сугыш чыга. Әтисе Габдулла сугышның беренче көненнән үк фронтка китә һәм шул китүеннән кире әйләнеп кайтмый, хәбәрсез югала. Мансура белән энесе Мансур әниләре Рәхимә һәм динне-көнне белүче әби-бабай кулында үтә тыйнак, итәгатьле һәм миһербанлы балалар булып үсәләр.

Мәктәпне яхшы билгеләренә генә бетереп, Мансура Алабуга пединститутында укый, белгечлеге буенча рус теле һәм әдәбияты укытучысы булырга хыяллана. Институтны тәмамлагач, Бөрешле, Песәй мәктәпләрендә эшли. 1957 елдан Бәзәкә мәктәбендә укыта башлый һәм үзен бик тырыш, яңага омтылучы, инсафлы зат итеп таныта.

Мансура Әхмәтова һәр үткәргән дәресен укучыларның танып-белү активлыгын камилләштерүгә, рус телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә, укучыларында белемне мөстәкыйль туплау ихтыяҗы булдыруга юнәлтә.

Татар балалары рус телендә дөрес һәм иркен сөйләшә алсыннар өчен, мөгаллимә программаларның барлык темалары буенча карточкалар, дидактик материаллар әзерли, диафильмнар туплый. Сүзлек белән эшләргә өйрәтүгә зур игътибар бирә, балаларны өстәмә әдәбият укуга аеруча нык җәлеп итә, ачык дәресләр бирә.

Укыту белән беррәттән, Мансура Әхмәтова рус теле укытучыларының методик куст берләшмәсен житәкли, күпсанлы доклад, лекцияләр укый. Авылда гына түгел, район күләмендә коллегалары арасында олы ихтирамга лаек була. Аның эш тәжрибәсе күпләргә үрнәк булып тора.

Җәмәгать эшеннән дә читтә калмый ул: концерт, спектакльләрдә актив катнаша, тамашачы күңелен яулап, өздереп бии.



Сыйныф җитәкчесе буларак та мөгаллимәнең тәрбиягә авыр бирелүче яшүсмерләр белән якыннан торып аңлашуы, баланың рухи үсешен тәэмин итәрдәй дөрес юнәлеш бирү юллары, аларның ата-аналары белән тыгыз элемтәдә булып, шәхси эшләү алымнары яхшы нәтиҗәләргә китерә. Гаиләләрендә үтә киеренке мөнәсәбәтләр булган Сәгинур, Шамил исемле кыз һәм малайларны Мансура зур көч, түземлелек һәм үҗәтлек белән мәктәпкә китертүгә ирешә, алга таба аларның язмышларын уңай якка үзгәртә. Бу турыда 60 нчы еллар азагында "Азат хатын" журналында журналист Д.Зөбәерова "Озын чәчле мөгаллимә" дигән мәкалә дә язып чыккан иде.

Тырыш, эзләнүчән, кызыклы һәм нәтиҗәле эш алымнарын табарга омтылучы Мансура Әхмәтова, гади укытучы гына булу кысаларыннан чыгып, гыйльми эш белән шөгыльләнергә ният кыла. 1968 елда Мәскәүгә китеп,

РСФСР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр буенча фәнни-тикшеренү институтында эшли башлый. Ул елларда үзенең эш тәҗрибәсен чагылдырган татар балаларын рус теленә өйрәтү методикасына кагылышлы байтак мәкаләләре "Совет мәктәбе" (хәзерге "Мәгариф") журналында басылып чыга.

Булачак фән эшлеклесе М.Әхмәтова Мәскәүдә эзләнү-тикшеренүләр дөньясына чума. Ул телгә багышланган төрле рефератлар, докладлар яза, аларны уку өчен Ленинград, Грозный, Ташкент, Казан, Уфа калаларында конференцияләрдә, педагогик укуларда катнаша. Аның гыйльми эше "Развитие речи учащихся как основа обучения русской орфографии в татарской школе" дип атала. Фәнни җитәкчесе – педагогия фәннәре докторы, профессор Л.З.Бакеева, рәсми оппонентлары профессор А.В.Дудников һәм педагогия фәннәре кандидаты Р.Б.Сабаткоев булалар.

Шулай итеп, алга куелган максатларга ирешү юлыннан уңышлы барган бер мәлдә, Мансура Әхмәтова алдына авыр чир мәкерле киртә куя һәм, озак та үтми, аны безнең арабыздан алып та китә.

Мансура апа! Озын кара толымнарыгыз, зифа буйсыныгыз, күбәләктәй җиңел йөрешегез белән табигатьнең иң гүзәл кошы – аккош кебек, ак һәм пакь зат булып, укучыларыгыз һәм авылдашларыгыз хәтерендә мәңге сакланасыз.

Урыныгыз җәннәт түрләрендә булсын, озын чәчле кадерле Мөгаллимә!



Мансура апа стоит с середине, сидят Габдулхай абый Миннехазиев

с сыном Завдатом на коленах, Нагим абый Ахметсахипов